Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында гражданнар җыены

21.11.2025 КАРАР №4

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә
авыл җирлегенең Ык Тамагы торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 2 нче номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Ык Тамагы авылындагы юлларны кардан чистарту . ЫкТамагы авылына вак таш сатып алу, ташу, тигезләү.
- Урамнарны яктырту җайланмасы (ЫК Тамагы авылында яктырткычлар сатып алу, Ык Тамагы авылында урамнарны яктырту җайланмасын урнаштыру).
- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү; (Ык Тамагы авылында үлән чабу хезмәтләре күрсәтү)

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов